ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422649, с. Бетьки,
ул. Мира, дом 11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘТКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422649, Бәтке авылы,
Тынычлык урамы, 11 нче йорт

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, e-mail:bet.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.r

---

КАРАР № 4

Бәтке ав. 2016 елның 1 феврале

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Бәтке авыл җирлеге Советы белән берлектә түбәндәге сораулар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә:

2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?

- Бәтке авылы җирлегенә керүче авыл урамнарының юлларын төзекләндерү өчен: Бәтке авылы, Яшьләр урамы -150м.; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы – 100м.; Мәктәп урамы-250м.;Кече Укмас авылы, Гагарин урамы -100м.;

-Бәтке авылы Тынычлык һәм Чокыр урамнарында 420 метр озынлыкта су торбаларын алыштыру;

- Киек авылында су башнясына суыргыч насос алу;

- урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампочкалар сатып алу - 70данә;

- Кече Укмас авылы зират коймасын тотып алу өчен (200м.).

ЭЙЕ ЮК

1. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

2. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов